**ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ ВЫСОКОГОРСКОГО МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН**
Кооперативная ул., 5, пос. ж/д станция Высокая Гора, Высокогорский район, Республика Татарстан, 422700

**ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ БИЕКТАУ МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ БАШКАРМА КОМИТЕТЫ**
Кооперативная ур, 5, Биектау т/ю станциясе поселогы, Биектау районы, Татарстан Республикасы, 422700

Тел.: +7 (84365) 2-30-61, факс: 2-30-86, e-mail: biektau@tatar.ru, www.vysokaya-gora.tatarstan.ru

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**
**от 16.12.2020** **№ 943**

## 2021 елга муниципаль берәмлек балаларын йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең нормативларын раслау турында

Татарстан Республикасы Министрлар Кабинетының 2010 елның 05 июлендәге 545 номерлы «Балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыруны финанслау нормативларын исәпләү буенча Методик тәкъдимнәрне раслау турында» карарының 3 пункты нигезендә, шулай ук белем бирү учреждениеләре укучыларын йөртүне гамәлгә ашырганда автомобиль транспортыннан файдалануның нәтиҗәлелеген арттыру максатларында, Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы Башкарма комитеты КАРАР БИРӘ:

1. 2021 елга кушымталарны расларга:

балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү хезмәте бәясе нормативларын (1 нче кушымта);

балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмә (2 нче кушымта).

2. «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы» МКУна балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча гомуми белем бирү оешмаларын финанслауны муниципаль хезмәт күрсәтүнең әлеге карарның 1 пунктында расланган бәясе нормативлары нигезендә тәэмин итәргә тәкъдим итәргә.

3. Әлеге карарны Биектау муниципаль районының рәсми сайтында http://vysokaya-gora.tatarstan.ru/ һәм Татарстан Республикасының хокукый мәгълүмат порталында http://pravo.tatarstan.ru бастырып чыгарырга (халыкка җиткерергә).

4. Әлеге Карарның үтәлешен контрольдә тотуны башкарма комитет җитәкчесе урынбасары - «Татарстан Республикасы Биектау муниципаль районы башкарма комитетының мәгариф бүлеге» муниципаль казна учреждениесе башлыгы Н.К. Әхмәтҗановка йөкләргә.

Биектау муниципаль районы
Башкарма комитеты җитәкчесе Д.Ф. Шәйдуллин

1 нче кушымта

Расланды
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 16 декабрендәге
943 нче номерлы
Карары белән

2021 елга балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтү хезмәте бәясе нормативлары

| Автотранспорт чарасының моделе атамасы | Ике ставкалы номативы күләме | |
|---|---|---|
| | бер автотранспорт чарасына ставка, елга сум | автотранспорт чарасының бер километр узуына ставка, елга сум |
| КАВЗ | 116398 | 37,42 |
| ПАЗ | 116656 | 37,35 |
| ГАЗ «Газель» | 110767 | 30,41 |
| УАЗ | 110314 | 29,04 |
| FIAT | 110057 | 27,47 |
| Peugeot Boxer | 110572 | 27,11 |
| Ford Transit | 110829 | 30,37 |
| Камаз Марко-Поло3297 | 119128 | 35,31 |

2 нче кушымта
Расланды
Биектау муниципаль районы
Башкарма комитетының
2020 елның 16 декабрендәге
943 нче номерлы
Карары белән

Балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәясен исәпләү тәртибе турында нигезләмә

Гомуми нигезләмәләр

1.1. Әлеге Нигезләмә балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру буенча муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәясен исәпләү механизмын (алга таба - муниципаль хезмәт) билгели.

1.2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе муниципаль хезмәт күрсәтү бәясенең, автотранспорт чаралары санының һәм хисап чорына автотранспорт чараларының фактта йөрүенең нормативы нигезендә исәпләнә.

1.3. Муниципаль хезмәт күрсәтүнең бәясе нормативлары ел саен «Биектау муниципаль районы» муниципаль берәмлеге башкарма комитеты тарафыннан раслана.

1.4. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен формалаштырганда автотранспорт чараларының факттагы йөреше турында мәгълүмат Татарстан Республикасында автотранспорт чараларының аерым төрләрен мониторинглауның бердәм системасы мәгълүматлары буенча, автотранспорт чарасының расланган паспорты кысаларында башкарылган хисап елында автотранспорт чарасының факттагы йөреше буларак кабул ителә.

2. Муниципаль хезмәт күрсәтү бәясен исәпләү

1.5. i-муниципаль берәмлекнең муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе түбәндәге формула буенча исәпләнә:

$$S_i = \sum_{m=1}^{k} (n_{f\,m} \times NF_{km_m} + NF_{as\,m} \times M_m),$$

монда:

$S_i$ –муниципаль хезмәт күрсәтү бәясе;

$n_{f\,m}$ - m, моделе автотранспорт чараларының фактик йөгереше, километр;

$NF_{km_m}$ - балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем

бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру бәясенең ставкасы бер километрга, сум;

$NF_{as\,m}$ - балаларны йөртү өчен махсус билгеләнгән автобусларда гомуми белем бирү оешмалары укучыларын йөртүне оештыру бәясенең бер автотранспорт чарасына ставкасы, сум;

$M_m$ - $m$ модельле автотранспорт чаралары саны, берәмлек;

$m$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобус моделе номеры;

$k$ - муниципаль берәмлектә кулланыла торган автобуслар саны.